| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ПОТАПОВО-ТУМБАРЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ПОТАПОВО-ТОМБАРЛЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Потап-Томбарлы авылы

10.08.2018ел. № 65

Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы
Потап-Томбалы авыл җирлеге
составына керүче торак пунктларда
гражданнар җыенын әзерләү
һәм үткәрү тәртибе турында
Нигезләмәне раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының "Потап-Томбалы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Потап-Томбалы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Потап-Томбалы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне (кушымта) расларга.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Потап-Томбалы авыл җирлеге башлыгы А.М. Килячков